**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6681**
**14.11.2018**

Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5948 нче карары белән расланган законлы вәкилгә балигъ булмаган затның акчалата кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5948 нче карары белән (Башкарма комитетның 2014 елның 13 августындагы 4754 нче, 2017 елның 19 октябрендәге 6348 нче карарлары редакциясендә) расланган законлы вәкилгә балигъ булмаган затның акчалата кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктның 11 абзацындагы «2007 елның 19 февралендәге 150 нче» сүзләрен «2014 елның 11 мартындагы 147-р санлы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2.15 пунктның икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлегенең күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

- бинаның җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;

- кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеп алу гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;

- мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә Башкарма комитетның мәгълүмат ресурсларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:

- документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә документлар биргәндә чиратлар;

- дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозулар;

- дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр;

- дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документларны кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра.»;

2) 3 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге пунктлар белән тулыландырырга:

«3.11. Дәүләт хезмәтен КФҮ аша күрсәтү.

3.11.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен КФҮгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.11.2. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.11.3. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен КФҮгә документлар кергәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3-3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.»;

4) 5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук КФҮнең, КФҮ белгечләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе.»;

5) 5.1 пунктта:

- беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар Башкарма комитетның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарына, эш итүенә (эш итмәвенә) судка кадәр тәртиптә – Башкарма комитетка, КФҮ белгечләре буенча – КФҮгә яисә КФҮне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.»;

- 3 пунктчадагы «каралмаган документларны» сүзләрен «тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә эшләрне гамәлгә ашыруны» сүзләренә алмаштырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге сигезенче, тугызынчы һәм унынчы пунктчалар белән тулыландырырга:

«8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән, 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән мәгълүматны таләп итү.»;

6) 5.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон төрдә бирелә.

Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), КФҮнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.»;

7) 5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ белгеченең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.»;

8) 5.4 пунктта:

- 1 пунктчаны «муниципаль хезмәткәр,» сүзләреннән соң «КФҮ, аның җитәкчесе һәм (яки) белгече,» сүзләре белән тулыландырырга;

- 3 пунктчаны «, КФҮ, КФҮ белгече» сүзләре белән тулыландырырга;

- 4 пунктчаны «, КФҮ, КФҮ белгече» сүзләре белән тулыландырырга;

9) 5.7 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.»;

10) 5.8 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче һәм өченче абзацлар белән тулыландырырга:

«Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән җавапта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, КФҮ яисә 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.»;

11) 5.9 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.»;

12) 5.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.10. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, КФҮнең, КФҮ белгечләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин